# ИГЕНЧЕНЕҢ УНЫНЧЫ ЯЗЫ

Колхозның партия оешмасы секретаре В. А. Паруков кулындагы төргәкне каршыга килүче тракторчыга тоттырды.

—Менә, Николай Федорович, сезгә истәлеккә.

Рәсемнән карап торган туры карашлы, ачык йөзле сурәттән Николай Федоровичның үзен таныйм. Узган ел рәсем район Мактау тактасында торган икән. Димәк, урта кул кеше генә түгел Краснов дигәннәре?

Сүземә каршы бермәлгә «Большевик» колхозының Ерепкино бригадасындагы механизаторлар йорты гөр килеп алды: барысы да Краснов турында сөйли.

—Гомерлек механизаторыбыз инде.

—Теләсә нинди эштә аңа таянырга була.

—Гаҗәп намуслы, башкаручан, тынгысыз кеше.

Ә аннан истәлекләр китте. Кайчан колхозга эшкә килде әле ул? Ә, 1957 нче елда. Башта әтисе белән бергә көтү көтте, аннан фермада терлекче булып эшләде. Хәрби хезмәттән кайткач, егет Бөгелмәдәге 7 нче СПТУны тәмамлады һәм шуннан бирле ул техникадан аерылмый. Иң элек иске МТЗ-5тә эшләде, аннан Т-40 ка күчте. Техниканы бик карап, ремонтлап эшләгәнгә, 11 ел тугры хезмәт куйды әлеге трактор. Гомумән, кайберәүләр кебек техника яңа чакта аны ордым-бәрдем ясап, аннан зарланып йөрүчеләрдән түгел Николай Федорович. Шуннан соңгы Т-4 не дә 8 ел эксплуатацияләде, инде менә ДТ-75 белән эшли. Авыл механизаторының хезмәте билгеле инде! Терлекчелектә дә алар кирәк, йөк ташуда да. Әмма төп хезмәт урыны, әлбәттә, басулар.

—Быел унынчы чәчүем, —ди Николай Федорович үзе турында сорауларга биргән кыска җаваплары арасында. Унынчы яз инде ул җир сулышын тыңлап, кайчак яңгыр, кайчак кояшлы аяз көннәр көтеп яши. Әле алдагы көннәрдәге яңгырдан соң суытып җибәргәч, җаны өшеп киткәндәй булган иде. Кара ходайның рәхмәтен: бүгенге җылылыкта җир нинди ләззәт белән коена, ужымнарның күзләре ачылган, игенчеләрнең дә йөзе-кәефе бүтән. Димәк, иртән кырга чыгарга була. Моңа кадәр Николай Федорович ужымнарны тукландыруда эшләде, норманы үтәми калганы булмады, тик җирнең тигез өлгермәве генә кәефне китеп торган иде. Малае Петрга да борчылып язган иде әле. Тегесе дә бит хат саен һаман бер сорауны яза: чәчү ничек? Тракторлар ничек? Николай Федорович андый хатлардан бик канәгать кала: әһе, малай актыгы, игенчеканы синдә, җирдән ерак китә алмассың, дип үзалдына сөйләнә. Шулай булыр да әле. Петр армиягә кадәр 99 нчы СПТУны тәмамлады да әтисе белән бергә тракторда эшләде. Әти кеше яхшы хәтерли: әлеге яңа ДТ-75не Норлаттан аның белән бергә алып кайтканнар иде. Юл буе улы әтисен кисәтеп кайтты: болайрак тот, тегеләйрәк бор. Яңа техникага малайларча сокланып каравын, аны сакларга, кадерләргә теләвен күреп тә шулай сөенгән иде Николай Федорович. Яшь кешедә ул сыйфат бар икән, димәк, ул үз-үзенә хилафлык итмәячәк. Ул аны гына чамалый инде, ничә кешене һөнәргә өйрәтте. Әнә бригададагы яшьләрдән Виталий Соловьев, Анатолий Абрамов, Александр Улаев ничек күз алдында нығып, тәҗрибә туплап киләләр. Караган саен сөенеп туя алмыйсың бит!

Бусы—малай хатыннан туган чигенү генә. Чәчү хәлләрен, вакыты тыгыз булса да, язмыйча булдыра алмый улына Николай Федорович. Быел ул чәчүчеләр Александр Соловьев һәм Георгий Максимов белән бергә эшли. Тегеләр үзләре шулай сораганнар, бик килешеп эшлиләр. Хәер, Красновның характеры теләсә кем белән янәшә эшләрлек сабыр, тыныч. Тик бер ягы бар, үзе дә астан-өстән генә эшләгәннәрне сөйми, янәшәдәгеләргә дә юл куймый. Яшьтәше, трактор бригадасы бригадиры Петр Константинович Илюшкин сүзләре бу.

—Эшкә иң иртә килүче, иң соң китүче дә ул. Хәер, алар икәү—Василий Алексеевич Абрамов та шулай ук.

Бәлки әле аларның дуслыклары шул уртак сыйфаттан киләдер дә. Василий Алексеевичның малае Анатолий да Красновның Петясы кебек үк СПТУда укый. Әле менә III курс укучысы әтисе янында практика үтә. Өлкән Красновларга, Абрамовларга алмаш килер төсле—механизатор һөнәрен СПТУда 15 стипендиаты үзләштерә «Большевик»ның.

..Җирдән күтәрелгән җиңелчә җылы парга, җәйге көн төсле тәннәрне эретерлек җылылыкка карап большевиклылар хыялланалар: әнә ужымнар нинди матур күтәрелгәннәр, техника әйбәт төзәтелгән, кәефләр яхшы. Эх, уңышны бер 35 центнерлап аласы иде, ә? Яки 30. Ә нигә, чынга ашмас хыял түгел бит бу. Әнә узган ел борчак гектарыннан 38 әр центнер уңыш бирде. Шул ук игенчеләр хезмәте нәтиҗәсе бит бу. Тагы крестьян хуҗалыгы дип җирне бүлгәләмәкче булалар. Ярый ла ул Красновлар төсле җир кадерен белгән кешегә эләксә. Юкса, бүлгәләп, яргалап аны рәнҗетәсе, харап итәсе дә түгел. Күбрәк кадерлисе, күбрәк тир генә түгәсе—җир бурычлы булып калмый.

«Большевик» колхозы механизатор агайлары шулай гәпләшteләр. Тәҗрибәле механизатор Николай Федорович Краснов та алар белән килеште. Киләчәк уңышка зур өмет тотып эшли ул быел. Ни дисәң дә унынчы игенченең юбилей язы бит быел аның.

**С. ХӘЙРУЛЛИНА.**



## Алдынгыларның берсе

10 ел буена сөт ташу машинасында «Татарстан» колхозының сөт ташу машинасы шоферы Ришат Мидхәтович Гыйльметдинов бу еллар эчендә йөз меңләгән километр юл үткәндер. Чөнки Норлат-Октябрь сөт-май комбинаты белән Кычытканлы арасы 60 километрдан артык. Ә Ришат Мидхәтовичның бирегә килми калган көне юк. Ул савылган һәм суытылган сөтне көн саен комбинатка китерә. Аның гаебе белән тоткарлык булганы һәм сөтнең бозылуына юл куелганы булмады. Шофер үз эшен үтә җаваплылык белән башкара. Аңа ара ераклыгы да, юлсызлык та комачауламый. Ә бит ул эшли башлаганда асфальт юллар турында хыяллана гына иде халык. Хәер, әле бүген дә авылдан олы юлга чыгу язын һәм көзен шоферлар өчен зур кыенлыклар тудыра. Ләкин үз һөнәренә тугрылыклы егет авырлыклар алдында баш ими.

**ТАНЫШ БУЛЫГЫЗ: Мария Ивановна һәм Владимир Михайлович Абрамовлар—«Знамя Октября» колхозының гомерләрен авыл тормышына багышлаган яшь гаиләләреннән берсе. Хезмәттә дә, гаиләдә дә татулык һәм уңыш юлдаш аларга. Элегрәк Владимир Михайлович тракторчы булып эшләде, ә аннан хатыны белән бергәләп дуңгызлар карауга күчте. Менә 5 еллап инде алар шул эштә матур гына күрсәткечләргә ирешәләр. Тормышларыннан да канәгатьләр: колхоз биргән зур таш йортта торалар, терлек-туар асрыйлар, бакча утырталар, балалар үстерәләр.**



**—Авылда да яшәп була, —диләр Абрамовлар бертавыштан.—Бары тик.. Без өстибез: бары тик авылны яратырга һәм эшләргә иренмәскә генә кирәк!**

## КПСС сафларында—50 ел

## Билге тапшырылды

Районның Савин авылында туган партия, сугыш һәм хезмәт ветераны Минсабир Нуретдинович Нуретдинов—үз гомерендә күпне күргән ветеран. Хезмәт юлын Төрнәс совхозында слесарь булып башлый. Ул чакта аңа нибары 14 яшь була. Хезмәткә, белемгә омтылышын, максатчанлыгын күреп, 1933 елда аны Казанга совет-партия мәктәбенә укырга җибәрәләр. Аны тәмамлап кайткач беркадәр вакыт профсоюз эшендә була. Күп тә үтми аны кабат башкалага— татар югары коммунистик авыл хуҗалыгы мәктәбенә тәкъдим итәләр.

Мәктәпне тәмамлап кайткач күп эшләргә туры килми аңа, 1939 елда Кызыл Армия сафларына чакырыла. Биредә 1941 елның мартында 22 кавалерия дивизиясе парткомиссиясе тарафыннан ул КПСС сафларына кабул ителә.

Бөек Ватан сугышының беренче көннәреннән ул алгы сызыкта: бронемашина командиры, танк полкы политругы урынбасары вазифаларын башкара, фашистлар, ә соңрак япон самурайлары белән сугыш хәрәкәтләрендә дә турыдан-туры катнаша.

1945 елның азагында гына тыныч хезмәткә кайта ала Минсабир Нуретдинович. Һәм күп төрле партия, совет, профсоюз һәм хуҗалык органнарында җаваплы эшләр башкара. Намуслы фидакарь хезмәте һәм сугышчан батырлыклары өчен ул байтак хөкүмәт бүләкләренә лаек була.

Күтәтән түгел авыл хуҗалыгы идарәсе коммунистларының ачык партия җыелышында Минсабир Нуретдиновичны тормышында истәлекле дата—партия сафларында 50 ел тору белән кайнар котладылар. Аны шулай ук КПСС райкомы бюросы исеменнән партия район комитетының икенче секретаре Ә. В. Мөлеков тәбрикләде һәм аңа шуны раслаучы билге, кыйммәтле бүләк тапшырды.

**Р. САДЫЙКОВ,**
авыл хуҗалыгы идарәсе партия оешмасы секретаре.

## Максат бер

Авыл кешесе ел әйләнә хәзерләнеп көткән вакыт—чәчү җитте. Аңа безнең колхоз игенчеләре чынлап та ныклап хәстәрләнделәр. Һәр бригадада слесарьлар группасы тагылма инвентарьны сафка бастырып куйды. Һәр механизатор үзе эшли торган техниканы үзе көйләде. Орлыкларыбыз да чәчү стандарты таләпләренә җавап бирә. Ягулык салу, эретеп ябыштыру агрегатлары басуда хезмәт күрсәтә.

Шуңа басуда кыр эшләре оешканлык белән башланып китте. Дым каплатуга 9 агрегат чыкты. Наил һәм Усман Заһретдинов, Гариф Хөснелгатин, Рәмис Сафин һәм башкалар да трактор керә алган кырларда аны тиз башкардылар.

Бер үк вакытта ужым һәм күпьеллык үлән культураларын тамырдан тукландыру алып барылды. Бу чараны Закирҗан һәм Галимҗан Хәмитшин агрегатлары кызу тоттылар.

Элек басуда, балчыкка чәчкән—уңган, дигән әйтем буенча эш итәләр, ягъни тырмалау бетүтә культивацияләү башлана иде. Шул сәбәпле басулар чүпләнде, аны солыча басты. Хәзер туфрак җылынганчы, чүп-үләннәр шытканны көтеп эшлибез.

Әмма басуда эш бетеп тормый. Кырларны чистарту, аерым участокларны шлейфлау, салам калдыкларыннан тазарту алып барыла. «Октябрьскагропромхимия»дән килгән техника катнаш азык чәчеләсе мәйданнарга ашлама һәм аммиак суы кертү белән мәшгуль. Ындырда орлык агулау алып барыла. Орлыкны чәчүгә хәзерләүдә Мәйсәрә Галиуллина, Җәмилә Мингалимова, Гөлсирә Ногъманова катнашалар.

**Н. ГАТАУЛЛИН,**
Ульянов исемендәге колхоз партия комитеты секретаре.

